**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПЕСЧАНО-КОВАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422625 с. Песчаные Ковали,
ул. Октябрьская,д.9а
тел: 8 84378 4-56-47
тел: (факс) 8 84378 4-56-41
E-mail: Pkov.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАИШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КОМЛЫ КОВАЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422625 с. Комлы Ковал авылы,
ул. Октябрьск урамы, 9 а нчы йорт,
тел: 8 84378 4-56-47
тел: (факс) 8 84378 4-56-41
E-mail: Pkov.La@tatar.ru

**2023 елның 07 декабре** **27 номер**

# КАРАР

**«Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 07 июлендәге 7 номерлы Комлы Ковал авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

РФ Хөкүмәтенең "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә, Комлы Ковал авыл җирлегенең Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 07 июлендәге 7 номерлы карарга үзгәрешләр кертергә:

**3.3.2.1 пунктындагы 11 абзацны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә.:

"Формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан сорауның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында башкарыла. Бердәм портал тарафыннан дөрес тутырылмаган электрон формадагы сорау кыры ачыкланганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры сорауның электрон формасындагы мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.";

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Комлы Ковал авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

**Җитәкче** **Н.С. Гыйлаҗетдинова**